ГОСУДАРСТВЕННЫЙ КОМИТЕТ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН ПО ТАРИФАМ

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫНЫҢ ТАРИФЛАР БУЕНЧА ДӘҮЛӘТ КОМИТЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

05.12.2025 г. Казань № 391-52/тэ-2025

Габишево авылы кулланучылары өчен «Инженерные Технологии» ремонт-төзелеш компаниясе» җаваплылыгы чикләнгән җәмгыяте тарафыннан җибәрелә торган җылылык энергиясенә (егәрлегенә) Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитетының 08.12.2023 ел, №440-28/тэ-2023 карары белән билгеләнгән тарифларны 2026 елга төгәлләштерү турында

«Җылылык белән тәэмин итү турында» 2010 елның 27 июлендәге 190-ФЗ номерлы федераль закон, Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Җылылык белән тәэмин итү өлкәсендә бәя кую турында» 2012 елның 22 октябрендәге 1075 номерлы карары, Федераль тарифлар хезмәтенең «Җылылык белән тәэмин итү өлкәсендә җайга салынулы бәяләрне (тарифларны) хисаплау буенча методик күрсәтмәләр раслау турында» 2013 елның 13 июнендәге 760-э номерлы боерыгы, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2010 елның 15 июнендәге 468 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитеты турында нигезләмә, Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитеты идарәсе утырышының 05.12.2025 ел, №30-ПР беркетмәсе нигезендә һәм 2026 елга җайга салынулы оешманың планлаштырылган кирәкле тулай керемен тәгаенләштереп, 2026 елга җылылык энергиясенә (егәрлегенә) тарифларны төгәлләштерү максатларында, Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитеты КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитетының «2024-2028 елларга Габишево авылы кулланучылары өчен «Инженерные Технологии» ремонт-төзелеш компаниясе» җаваплылыгы чикләнгән җәмгыяте тарафыннан җибәрелә торган җылылык энергиясенә (егәрлегенә) тарифлар билгеләү турында» 08.12.2023 ел, №440-28/тэ-2023 карары (Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитетының 13.12.2024 ел, №452-49/тэ-2024 карары нигезендә кертелгән үзгәрешләре белән) белән Габишево авылы кулланучылары өчен «Инженерные Технологии» ремонт-төзелеш компаниясе» җаваплылыгы чикләнгән җәмгыяте тарафыннан җибәрелә торган җылылык энергиясенә (егәрлегенә) билгеләнгән тарифларны 2026 елга төгәлләштереп, 1 нче кушымтаны яңа редакциядә (кушымтада) бирергә.

2. Әлеге карарның 1 пунктында төгәлләштерелгән тарифлар 2026 елның 1 гыйнварыннан 2026 елның 31 декабренә кадәр гамәлдә була.

3. Бу карар рәсми басылып чыккан көненнән башлап 10 көн узгач үз көченә керә.

Рәис Р.В. Гайнетдинов

Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитетының 08.12.2023 ел, № 440-28/тэ-2023 карарына 1 нче кушымта
(Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитетының 05.12.2025 № 391-52/тэ-2025 карары редакциясендә)

## Габишево авылындагы кулланучылар өчен «Инженерные Технологии» ремонт-төзелеш компаниясе» җаваплылыгы чикләнгән җәмгыятеннән кулланучыларга җиткерелә торган җылылык энергиясенә (егәрлегенә) 2024-2028 елларга календарь буенча бүленгән тарифлар

| т/с | Муниципаль берәмлек, җайга салынулы оешма атамасы, тариф төре | Ел | Су | Басым астында сайланма пар | | | | Кискен һәм редукцияләнгән пар |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | | | | 1,2 башлап 2,5 кг/см$^2$ кадәр | 2,5 башлап 7,0 кг/см$^2$ кадәр | 7,0 башлап 13,0 кг/см$^2$ кадәр | 13,0 кг/см$^2$ югары | |
| | Лаеш муниципаль районы | | | | | | | |
| 1 | «Инженерные Технологии» төзелеш-ремонт компаниясе» җаваплылыгы чикләнгән җәмгыяте, Габишево авылы <*> | | | | | | | |
| 1.1 | Кулланучылар өчен (тарифлар ӨХС исәпкә алып күрсәтелгән)<**> | | | | | | | |
| | бер ставкалы, сум/Гкал | 01.01.2024 башлап 30.06.2024 кадәр | 2 096,21 | - | - | - | - | - |
| | | 01.07.2024 башлап 31.12.2024 кадәр | 2 326,52 | - | - | - | - | - |
| | | 01.01.2025 башлап 30.06.2025 кадәр | 2 326,52 | - | - | - | - | - |
| | | 01.07.2025 башлап 31.12.2025 кадәр | 2 790,10 | - | - | - | - | - |
| | | 01.01.2026 башлап 30.09.2026 кадәр | 2 790,10 | - | - | - | - | - |
| | | 01.10.2026 башлап 31.12.2026 кадәр | 3 187,03 | - | - | - | - | - |
| | | 01.01.2027 башлап | 3 187,03 | - | - | - | - | - |

| | | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | | 30.06.2027 кадәр | | | | | | |
| | | 01.07.2027 башлап 31.12.2027 кадәр | 2 332,64 | - | - | - | - | - |
| | | 01.01.2028 башлап 30.06.2028 кадәр | 2 332,64 | - | - | - | - | - |
| | | 01.07.2028 башлап 31.12.2028 кадәр | 4 689,78 | - | - | - | - | - |

<*> Салым салуның гадиләштерелгән системасын куллана.
<**> Россия Федерациясе Салым кодексының 164 статьясындагы 8 пунктының 1 пунктчасында билгеләнгән салым ставкасын куллана.

Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитетының тариф карарларын кабул итүне оештыру, контрольдә тоту һәм теркәү бүлеге